**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

ПРИКАЗ — № 136/о — БОЕРЫК

«27» 12 2013г.

**“Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыру турында” Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 27.02.2012 41/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

“Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыру турында” Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 27.02.2012 41/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәне “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 27.07.2004 79-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, **боерык бирәм**:

1. “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыру турында” Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 27.02.2012 41/о номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.8 пунктта:

“31 статьяның 1, 2 һәм 3 өлешләре” сүзләрен “31 статьяның 1 өлеше һәм 60.1 статьяның 9 өлеше” сүзләренә алмаштырырга;

“конкурс нигезендә формалаштырылган кадрлар резервында торучы” сүзләрен “дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән” сүзләренә

алмаштырырга;

2.2 пунктта:

“Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Иҗтимагый совет” сүзләреннән соң “, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре,” сүзләрен өстәргә;

соңгы җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Бәйсез экспертларның һәм Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил итә.”;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

“Граждан хезмәте вазыйфасын биләүче конкурс комиссиясе әгъзалары катнашында конкурс комиссиясе утырышын уздыру рөхсәт ителми.”;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: “Министрлыкта конкурста катнашырга теләк белдергән Министрлык граждан хезмәткәрләренә министр исеменә гариза бирү җитә. Министрлыкта конкурста катнашырга теләк белдергән башка граждан хезмәткәрләре Министрлыкка министр исеменә гариза һәм, фотографияләрне кушып, граждан хезмәткәрләренең үз кулы белән язылган, имзасы салынган һәм үзе граждан хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт органының кадрлар хезмәте таныклаган, рәвеше Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган анкета тапшыралар.”;

Әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Граждан конкурста катнашуга түбәндәге очракта кертелми:

а) закон көченә кергән суд карары белән хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган;

б) дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәү мөмкинлеге юк ителгән җәзага, закон көченә кергән суд карары буенча җәзага хөкем ителгән очракта, шулай ук федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә кире кагылмаган һәм юкка чыгарылмаган хөкем ителеше булган очракта;

в) әгәр граждан биләргә дәгъва белдергән граждан хезмәте вазыйфасы буенча яисә граждан хезмәткәрләре тарафыннан биләнә торган вазыйфа буенча граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен һәм федераль закон белән саклана торган серне тәшкил итүче белешмәләрне куллануга бәйле булса, шундый белешмәләрне алуны рәсмиләштерү процедурасы узудан баш тарткан;

г) граждан хезмәтенә керүгә яисә аны узуга каршы килерлек һәм медицина учреждениесе бәяләмәсе белән расланган авыруы булган;

д) граждан хезмәте вазыйфасын биләү граждан хезмәткәренең якын туганы яисә туган-тумачасы (ата-аналары, ире яисә хатыны, балалары, абый-энеләре, апа-сеңелләре, шулай ук ире яисә хатынының абый-энеләре, сеңелләре, ата-аналары, балалары һәм балаларының ире яисә хатыны) берәрсенең турыдан-туры буйсынуында яисә контролендә булган;

е) Россия Федерациясе гражданлыгыннан киткәндә яисә башка дәүләтнең гражданлыгын алган;

ж) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе белән бүтәне каралмаган булса, башка дәүләтнең (башка дәүләтләрнең) гражданлыгы булган;

з) граждан хезмәтенә кергәндә ялган документлар яисә күрәләтә ялган белешмәләр тапшырган;

и) граждан хезмәтенә кергәндә федераль закон белән билгеләнгән белешмәләрне тапшырмаган яисә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында күрәләтә ялган белешмәләр тапшырган;

к) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу һәм аларны җайга салу турындагы чикләүләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәмәгән һәм, коррупциягә каршы көрәш максатларында, "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" 27.07.2004 79-ФЗ номерлы Федераль закон, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 25.12.2008 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән вазыйфаларны үтәмәгән очракларда, министр (эшкә яллаучы вәкиле) тарафыннан граждан хезмәткәренә ышаныч югалаган.";

Әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтаның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8. Дәүләт раждан хезмәтенә керүгә каршы килерлек авыруы булу (булмау) турында медицина учреждениесе бәяләмәсе (№ 001-ГС/у формасы).".

2. Юридик бүлек (Латыйпова Э.Ю.) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына законнарда билгеләнгән тәртиптә җибәрүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Министр** **И.Ә. Фәйзуллин**